КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 июнь г.Казань № 407

Казан шәһәре чикләрендәге Урта Кабан күле участогында «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын әзерләгәндә һәм уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендәге Урта Кабан күле участогында «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын әзерләгәндә һәм уздырганда кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елның 9 июненнән 24 июненә кадәр 7 сәгать 00 минуттан 20 сәгать 00 минутка кадәр «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын уздыру чорында Казан шәһәре чикләрендәге Урта Кабан күле участогында аз сыешлы судноларадан, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт һәм башка йөзә торган һәм буксирга ала торган чаралардан (гидроцикл, байдарка, ишкәкле көймәләрне кертеп) файдалану тыела;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән судноларадан файдалануны тыю Казан шәһәре чикләрендәге Урта Кабан күле участогында «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара мультиспорт чарасын әзерләүгә һәм уздыруга җәлеп ителгән судноларга кагыйлмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин